**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXIX СЕССИЯСЕ**

# К А Р А Р № 169

Мөслим авылы 2023 ел «16» ноябрь

**2024 - 2026 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставының 37 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024-2026 елларга Мөслим муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. 2024 елга Мөслим муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына муниципаль унитар предприятиеләрне үзгәртеп коруны әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә кертергә.
3. Күрсәтелгән мөлкәтне хосусыйлаштыру ысулын билгеләүне Мөслим муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Р. Ф. Хантимеровка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р. Хуҗин

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Советының 2023 елның
«16» ноябрендәге 169 номерлы
карарына 1 нче кушымта

2024 - 2026 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

1. Торак булмаган бина - склад
   Төзелеш елы: 1947 ел
   Гомуми мәйданы – 95,1 кв.м.
   Кадастр номеры 16:29:070402:266
   Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы,
   Мөслим муниципаль р-н, Вәрәшбаш авыл җирлеге һәм
   кадастр номеры 16:29:070402:265 булган җир кишәрлеге
   мәйданы 341 кв.м. адрес: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы,
   Мөслим муниципаль р-н, Вәрәшбаш авыл җирлеге.

2. Торак булмаган бина - склад
   Төзелеш елы: 1970 ел
   Гомуми мәйданы – 1112 кв.м.
   Кадастр номеры 16:29:100601:367
   Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы,
   Мөслим муниципаль районы, Симәк авыл җирлеге һәм
   кадастр номеры 16:29:100601:365 булган җир кишәрлеге
   мәйданы 1702 кв.м. адрес: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы,
   Мөслим муниципаль районы, Симәк авыл җирлеге.

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Советының 2023 елның
«16» ноябрендәге 169 номерлы
карарына 2 нче кушымта

2024 елгаТатарстан Республикасы Мөслим муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Хуҗалык белән тәэмин итү» муниципаль унитар предприятиесен ИНН 1629005686, ОГРН 1151651003096 җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Төзекләндерү һәм яшелләндерү» муниципаль унитар предприятиесен ИНН 1629004227, ОГРН 1071687000109 җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә үзгәртергә.